## Сихри кар

Бәзәкә китапханәсе каршында эшләп килүче “Күпбеләм” түгәрәгенең чираттагы эше кыш фасылы һәм кышның асыл бизәге кар бөртекләренә багышланган иде. Китапханәче бу көнне балаларга “Сихри кар” дигән бәйге-уен программасы тәкъдим итте.

Балалар иң элек кар турындагы викторина сорауларына җавап бирделәр, аннары ике төркемгә бүленеп төрле бәйгеләрдә ярыштылар, хәрәкәтле уеннар уйнап күңел ачтылар. Чара соңында китапханәче баллы күчтәнәчләр белән сыйлады, катнашучылар белемнәрен арттырып яхшы кәеф белән өйләренә таралыштылар. (февраль 2021 ел)




